КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 8 июль г.Казань № 802

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 - 2023 елларда Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны тормышка ашыру буенча чаралар турында» 2022 ел, 23 март, 258 нче карары белән расланган 2023 елда эш бирүчеләрнең яраклы эш эзләү максатларында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнар (эшсез гражданнарны кертеп) өчен җәмәгать эшләрен оештырганда хезмәт өчен өлешчә түләү чыгымнарын һәм оешмаларның эштән азат ителү рискындагы хезмәткәрләрен вакытлыча эшкә урнаштыруны оештырганда хезмәт өчен өлешчә түләү һәм матди-техник җиһазландыру чыгымнарын финанс белән тәэмин итү (каплау) тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 - 2023 елларда Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны тормышка ашыру буенча чаралар турында» 2022 ел, 23 март, 258 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 17 август, 846 нчы, 2022 ел, 14 сентябрь, 1001 нче, 2022 ел, 30 декабрь, 1488 нче, 2023 ел, 10 февраль, 129 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган 2023 елда эш бирүчеләрнең яраклы эш эзләү максатларында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнар (эшсез

гражданнарны кертеп) өчен җәмәгать эшләрен оештырганда хезмәт өчен өлешчә түләү чыгымнарын һәм оешмаларның эштән азат ителү рискындагы хезмәткәрләрен вакытлыча эшкә урнаштыруны оештырганда хезмәт өчен өлешчә түләү һәм матди-техник җиһазландыру чыгымнарын финанс белән тәэмин итү (каплау) тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Субсидия сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айның 1нче көненнән дә иртәрәк булмаган датага карата түбәндәге таләпләргә туры килә торган эш бирүчеләргә бирелә:».

2.3 пунктның алтынчы абзацында «сайлап алу үткәрү планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1 нче көненә» сүзләрен «сайлап алу үткәрү турында игълан урнаштырылган айның 1 нче көненнән дә иртәрәк булмаган датага» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин